# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**Карары**
**өченче чакырылыш утыз тугызынче утырышы**

**11 сентябрь ае 2019 ел** **№ 117** **Әбде авылы**

**Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

Теләче районы прокуратурасының "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2019 елның 28 мартындагы 02-08-01 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советының 09.06.2016 ел N 20 "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" (алга таба – Нигезләмә), (10.05.2017 ел N 31, 01.06.2017ел N 32, 25.12.2017 ел № 52, 20.12. 2018ел № 105 карарлар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1.) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Әбде авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә:

А) 5 Бүлектә:

- 2 пунктның 6 өлешен түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне, шул исәптән электрон документ рәвешендә теркәлүне раслый торган документ. Беренче тапкыр эшкә керә торган затка шәхси счет ачылмаган очракта, эш бирүче тарафыннан Россия Федерациясе Пенсия фондының тиешле территориаль органына күрсәтелгән затны индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәү өчен кирәкле белешмәләр тапшырыла.»;

Б)28 Бүлектә:

– 1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешманың сайланулы органы тарафыннан, идарәдә түләүсез нигездә катнашуга; съездда